РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 13 марты Кукмара ш. № 272

Кукмара муниципаль районы Советының 2019 елның 25 октябрендәге 249 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2019 елның 25 октябрендәге 249 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.11 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу»

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товар, эш, хезмәт күрсәтүләр сатып алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.»

1.2. 17 статьяда:

а) ундүртенче абзацта «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) уналтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 38 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләрне) билгели торган нигезләмәләре;
Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;
бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;
районның социаль-икътисадый үсеше фаразлары;
озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);
муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).»;
1.4. 42 статьяның 2 пунктындагы өченче абзацында «ике» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга;
1.5. 44 статьяның 2 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)) бюджет чыгымнарын классификацияләүнең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча яисә чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт (муниципаль) программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәр (төркемнәр һәм төркемчәләләр) буенча һәм (яисә) чыгымнар төрләренең максатчан статьялары (дәүләт (муниципаль) программалары һәм программага карамаган юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук, Бюджет Кодексында, Татарстан Республикасы Законында, район Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән очракларда, бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү;»;
1.6. 50 статьяда:
а) икенче абзацта «Федераль казначылык органнары счетларыннан» сүзләрен «керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларыннан» сүзләренә алмаштырырга;
б) дүртенче абзацта «салымнар һәм җыемнар турында» сүзләрен төшереп калдырырга;
в) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр бюджеты керемнәре администраторы тарафыннан төгәлләштерү;»;
г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
1. «- артык түләнгән яки артык алынган салым, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтару (зачет, төгәлләштерү) өчен кирәкле артык бүленгән суммаларны, акчаларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентлар суммасын һәм артык түләттерелгән суммаларга исәпләнгән процентлар суммасын Федераль казначылык тарафыннан керемнәрне исәпкә алу һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү өчен билгеләнгән тиешле бюджетларның бердәм

счетларыннан, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Федераль казначылыкның тиешле счетларына күчерү.»;

1.7. 51 статьяда:

а) 3 пунктта «түләү һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба – күрсәтмә) һәм» сүзләренә, «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга»;

б) 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне кабул итү һәм исәпкә алу»;

в) 4 пунктның беренче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктта «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга;

1.8. 52 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет йөкләмәләре чыгымнары һәм лимитлары буенча бюджет язмасы күрсәткечләре, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башына кадәр ведомство карамагындагы РБС һәм (яки) ПБСларга җиткерелә.»;

1.9. 56 статьяның 1 пунктында «һәм стандартлар» сүзләрен төшереп калдырырга, «билгеләнәләр» сүзен «билгеләнә» сүзе белән алмаштырырга;

1.10. 60 статьяда:

а) сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар, әлеге карарның 4 пункты белән үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. 1.2 пункты, 1.6 пунктның «а», «г» пунктчалары, 1.7 пунктның «а» пунктчасы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район Башлыгы Димитриев С. Д.